УДК 792:377

***Р.Р. Вәлиев***

# КАЗАНДА МАХСУС УРТА ТЕАТР БЕЛЕМЕ

Статья посвящена развитию театрального образования в Казани. В статье указаны основные этапы этого процесса, их особенности, освещены наиболее значимые проблемы как творческого, так и административного характера. Раскрывается роль театрального образования в культурном строительстве, показаны трудности и достижения, названы наиболее значимые имена.

**Ключевые слова:** среднее профессиональное театральное образование, театральное училище, театральный техникум.

Татарстан АССР 1920 елда төзелә. Республиканың туган көне татар театры бинасына нигез салыну белән дә истәлекле. Милли театрның беренче тапкыр дәүләт статусы алуы да шуннан башлана. 1922 елның 26 сентяберендә, Татарстан АССР һөнәри белем бирү коллегиясе карары нигезендә, татар дәүләт театрына белгечләр әзерләү максаты белән Татар театр техникумы ачыла.

Бу уку йорты белән идарә итү Зәйни Солтановка йөкләнә, шул ук вакытта ул, рус театрының күренекле режиссеры Зинаида Михайловна Славянова катнашы белән, оештыру эшләрен дә алып барырга тиеш була.

Беренче вакытларда техникумның үз бинасы да булмый. Аны Петропавловский (хәзер М. Җәлил) урамындагы «Идел» номерлары ишегалдына урнаштыралар. Техникумның аудиторияләре дә, тулай торагы да шунда була. Техникумның беренче директоры итеп инкыйлабка хәтле үк эшләгән театрның танылган артисты Зәки Баязидский билгеләнә. Аннан тыш, техникум укучылары арасыннан укучылар комитеты, аның рәисе итеп Хәким Сәлимҗанов сайлана. Директорлар бик еш алышына, 5 ел эчендә бу вазифада 5 кеше эшләп ала.

Зәки Баязидский 1923–1924 елларда эшли; 1924 елда аны Хәмит Солтанов алыштыра; 1925 елда – Юмай, 1925–1928 елларда М. Мәһдиев, ә 1928 елдан Муса Зәитов директор була.

Техникумда эшнең һәркайсын: уку-укыту планнарын һәм программаларын, көн тәртибен һәм тәртип кагыйдәләрен, сәхнә эше һәм театрлар тарихы буенча махсус дәреслекләрне – барысын да яңабаштан эшләргә туры килә.

Алар техникумның беренче завучы Б. Симолин җитәкчелегендә әзерләнә. Өч ел белем бирү курсын күздә тоткан программа профессиональ яктан әзерлек һәм тирән белемле белгечләр белән тәэмин итүгә юнәлдерелә.

Театр техникумының баштагы контингенты бу һөнәр белән кызыксынучылардан туплана. Кабул итү актерлык сәләте буенча имтихан аша оештырыла. Сәхнә артистлары әзерләүче махсус уку йортында Татарстан, Башкортстан, Кырым, Урта Азия регионнарыннан, Урал, Себер авылларыннан җыелган укучылар белем

ала. Уку елы башында укучылар саны 16 булса, ел ахырына алар инде 30 га җитә. Техникумны элеккеге кызлар өчен эшләгән Мария гимназиясе бинасына (хәзер Рәхмәтуллин урамы, 2, Петропавел соборына каршы почмак йорт) күчерәләр.

Техникумга укытучылар итеп театр сәнгатенең җирле иң яхшы белгечләре һәм педагоглар чакырыла. Алар арасында татарлар да (гомум белем һәм һәрьяклы үсеш фәннәре буенча), руслар да (театр фәннәре буенча) була. Беренче педагоглар – татар һәм рус сәхнәләренең күренекле эшлеклеләре Зәйни Солтанов (мөдир), Салих Сәйдәшев (җыр), Фатих Әмирхан (татар әдәбияты), Бари Тарханов белән Зинаида Славянова (сәнгатьле уку), Михаил Прыгунов (дөнья мәдәнияте тарихы). Географияне Мөхәммәтов, пластиканы Каракович, татар телен Биккулов, актерлык практикасын Тинчурин алып бара. Күптән түгел генә Зур театр студиясен тәмамлаган К. Романычева рус теле тарихын укытырга, булачак халык артисты В. Белокуров грим белән эшләүне өйрәтергә җәлеп ителәләр.

Беренче чыгарылыш 1926 елда була. Күренекле актерлардан Х. Сәлимҗанов, Г. Кайбицкая, Г. Булатова, Г. Нигъмәтуллина, драматург Риза Ишморат һ.б. заманында шушы техникумны тәмамлаган булалар. К. Бариев белән К. Тумашева техникумнан соң ук анда укытучы булып эшли башлыйлар. 1927 елның җәендә Г. Девишев белән И. Ингвар җитәкчелегендә бер төркем укучылар гастрольгә чыгалар.

Шул ук 1927 елда татар театр һәм сәнгать техникумнары берләштерелә һәм К. Маркс урамындагы бинага күчерелә. Бу уку йорты Казан берләштерелгән сәнгать һәм театр техникумы дип атала башлый. Шуны билгеләр үтү мөһим, ике уку йортын болай кушуның сәбәбе, беренчедән, чыгымнарны кыскарту, аннан рациональ файдалану булса, икенче яктан, бердәм техникум төзеп, бу өлкәләр буенча белем бирүне камилләштерүгә юл тоту дип санарга кирәк.

1929 елда техникумны ТАССРның булачак халык артистлары Галимә Ибраһимова, Габделгазиз Зыятдинов, шулай ук Луиза Салиәскәрова (соңрак ул техникумда укыта) тәмамлый.

1930/1931 уку елы барышында Казан берләштерелгән сәнгать-театр техникумы Көнчыгыш музыка техникумы белән берләштерелә һәм Татар сәнгать техникумы дип атала башлый. Техникум Жуков урамына урнаша. Анда театр, музыка, сәнгать бүлекләре эшли.

Төрле авырлыклар кичерүгә карамастан, 1923–1930 елларда Татарстанда театр, сәхнә сәнгате белеме бирү камилләшә һәм үзенең җимешләрен дә бирә. Театр техникумында укучылар, беренче елларыннан ук, академия театрында спектакльләрдә күмәк күренешләрдә катнаша башлыйлар. Аны тәмамлагач, академия театрында эшлиләр һәм күбесе күренекле артистлар булып танылалар.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Татарстанда театр белеме бирү туктап кала. Студентлар һәм техникумны тәмамлаучылар сугышка китә. Шулай итеп,

1941 елның җәендә Сәнгать техникумы бөтенләй ябыла.

1943 елда, фронт сызыгы әкренләп Көнбатышка күчә башлагач, татар артистлары әзерләү мәсьәләсе кабат күтәрелә.

«Татарстан АССРда театр сәнгате кадрлары әзерләү чаралары турында» ВКП(б) өлкә комитеты бюросының 1943 ел, 17 июль һәм ТАССР Халык Комиссарлары Советының 1944 ел, 1 март карарлары нигезендә Казанда Татар театр көллияте ачыла. Аның директоры итеп ТАССРның атказанган артисты С.С. Булатов билгеләнә (аңа 1200 сум күләмендәге персональ эш хакы раслана) [Милли архив. Ф. 5795, оп.1, эш 1, б. 2].

Әмма күрелгән барлык чараларга да карамастан, татар театр көллиятенә укучылар туплау эше һаман сузыла бара. Укулар 1945 елның 17 сентябрендә генә башлана.

1945/46 уку елы башында көллияттә 17 укытучы эшли: аларның 14 е – бер үк вакытта ике урында эшләүче, 11 е югары, 6 сы махсус урта белемле була. Исемдәрәҗәләргә ия 6 укытучы эшли. Актер осталыгы педагоглары Ширияздан Мөхәммәтҗан улы Сарымсаков белән Кәшифә Җамалетдин кызы Тумашева Дәүләт театр сәнгате институтының (ГИТИС) режиссерлык факультетын тәмамлап эшлиләр. Сәхнә телен Габдулла Шамуков (соңыннан СССР халык артисты) белән Луиза Салиәскәрова укыта, грим буенча Касыйм Шамил, биюләрне Петр Якушев, сәхнә хәрәкәтләрен Пейсахов, татар әдәбиятын КДУ профессоры Хатип Госманов укыта.

1949 елда Татар театр көллияте театрларыбызны беренче мәртәбә өстәмә көчләр белән тулыландыра. Шул елның җәендә СССРдагы татарлар күпләп яши торган шәһәрләргә һәм эшчеләр бистәләренә гастрольләр оештырыла.

Дүрт ел дәвамындагы киеренке эшләр һәм җитди белем бирү нәтиҗәсез булмый. 1949 елның 25 маеннан 1 июльгә кадәр күрсәтелгән диплом спектакльләре (алар – бишәү) чын-чынлап иҗади хисап тотуга әверелә. Ул спектакльләрнең һәркайсы күпсанлы тамашачыларны җәлеп итә (алар арасында дәүләт җитәкчеләре, җәмәгатьчелек вәкилләре, мәдәният һәм сәнгать хезмәткәрләре, язучылар, рәссамнар бар) [Милли архив. Ф. 5795, оп. 1, эш 49, б. 3]. Имтихан барган көннәрдә көллият тормышын һәм белем бирүне чагылдырган материаллардан махсус күргәзмә оештырыла. Дәүләт имтиханнарын тапшыру 30 студентның 28 енә рөхсәт ителә. Чыгарылыш имтиханнарын алты студент иң яхшы билгеләргә генә тапшыра. 1949 елгы чыгарылыш нәтиҗәләре көллияттә югары квалификацияле, дөрес методлар белән коралланган, яхшы педагоглар советы булган коллектив эшләвен раслый.

Шуны билгеләп үтәргә кирәк, 1949 елгы сугыштан соңгы чыгарылыш сәхнә реализмы нигезендә тәрбияләнә, һәм шушы елда кулына диплом алган яшьләр арасында эшли-эшли зур танылуга ирешүчеләр дә бар. Мәсәлән: Алсу Илялова, Рауза Ибраһимова, Айрат Арсланов СССРның халык артисты; Гата

Нуруллин – ТАССРның халык артисты; Шәүкәт Биктимеров – СССРның һәм Татарстанның халык артисты, К.С. Станиславский исемендәге Дәүләт һәм Г. Тукай исемендәге ТР Дәүләт премияләре лауреаты.

Татар дәүләт театр көллиятенең хезмәтләре нәтиҗәле булуга карамастан, СССР Министрлар Советының 1952 ел, 13 июнь карары белән ул эшләүдән туктатыла.

ТАССР Мәдәният министрлыгы һәм шәхсән министр Булат Миңнулла улы Гыйззәтуллин тырышлыгы белән 10 елдан соң ТАССР Министрлар Советының 1962 ел, 12 май карары нигезендә Казан театр көллияте [Милли архив. Ф. 5795, оп. 2, эш 1, б. 5] яңадан эшли башлый.

Яңа ачылган бу уку йортының директоры итеп күптән түгел Мәскәүнең М.С. Щепкин исемендәге театр көллиятен тәмамлаган Дамир Бәдретдинов билгеләнә.

1962/63 уку елында Казан театр көллиятенең белем бирү өчен үзенең матди базасы булмый. Дәресләр төрле урыннарда (Педагогика институтының икенче бинасында, Г. Камал һәм В. Качалов исемен йөрткән театрларда, «Динамо» спортзалында һәм Театр җәмгыяте бинасында) уздырыла. Тиздән, хезмәт ияләре депутатларының Казан шәһәр Советы башкарма комитеты карары (1963 ел, 30 март, № 200) белән Театр көллияте өчен Гоголь урамында ике йорт (№ 2а һәм 2/35) бирелә.

Әмма объектив һәм субъектив сәбәпләр аркасында башкарма комитет карары өлешчә генә үтәлә, чөнки күрсәтелгән биналарның төп өлешенә Республика ветеринария лабораториясе һәм тагын 15 гаилә урнашкан була. Театр көллияте 200 м$^2$ мәйданны биләгән 6 бүлмәдә генә эшләргә мәҗбүр була.

Театр көллиятендә директор һәм аның рәислегендәге педагоглар советы түбәндәге мөһим мәсьәләләрне хәл итә: театр көллияте бурычларын тормышка ашыру, укучыларның агымдагы өлгерешен тәэмин итү, имтихан сессияләренә әзерләнү, укучылар арасында алып барылган тәрбия эшләре буенча сыйныф җитәкчеләренең хисап тотуы, укытучыларның квалификациясен күтәрү һ.б. Педагоглар советы эшеннән тыш, актерлык осталыгы һәм сәхнә теле буенча циклы комиссияләр дә эшли [Милли архив. Ф. 5795, оп. 2, эш 14, б. 4].

Театр көллиятендә һөнәри белем бирү һәм актерлык тәрбияләү системасының нигезен театрның үз казанышлары, К.С. Станиславский белән И.Н. Данченконың, шулай ук аларның шәкертләренең педагогик һәм иҗади тәҗрибәләре тәшкил итә.

Көллиятнең дәрәҗәсе арта бара, моны анда укырга керергә теләүчеләрнең гаризалары саны раслый. Әйтик, 1966 елда татар актерлары әзерләү бүлегенә 137, курчак театры артистлары әзерләү бүлегенә 104 гариза кергән. Шулардан татар актерлары бүлегенә 25 кеше (14 егет һәм 11 кыз; 12 се урта белемле, 3 се 9 нчы сыйныфны, 10 сы 8 нче сыйныфны тәмамлаучы) кабул ителгән. Курчак театры бүлегендә 20 кеше (10 егет һәм 10 кыз; 6 сы урта белемле, 5 се 9 нчы сыйныфны, 9 ы

8 нче сыйныфны тәмамлаган) укый башлаган.

Көллиятнең һәм аны тәмамлап эшләүчеләрнең уңышлары хакында матбугатта басылып чыккан мәкаләләрдән укып та белергә мөмкин. Театр белгече К. Кривицкий «Театр учится у жизни» дигән мәкаләсендә көллиятне тәмамлап Татарстан АССР күчмә театрында эшләүче В. Хөснетдиновны мактап яза [Советская Татария. 1966. 14 июня]. В.И. Качалов исемендәге Казан театры спектакленә багышланган «Ради тебя... помни» дигән мәкаләдә театр белгече Золотарев көллиятне тәмамлаучылардан Н. Сикорова белән В. Кирюханцев иҗатына югары бәя бирә [Театральная жизнь. 1966. № 10]. «Они и мы» спектакленә язган рецензиясендә Бердичевский көллиятне тәмамлагач Казан яшь тамашачылар театрында эшли башлаган А. Кокурин һәм Жаворонкова турында «они не только доносят до зрителя мысли автора и режиссера, но и интересное собственное понимание образа» дип яза [Комсомолец Татарии. 1966. 30 июля]. Казан яшь тамашачылар театрында куелган «Мужчина 17 лет» спектакле буенча язган рецензиясендә филология фәннәре кандидаты Богдановның түбәндәге юлларын укый алабыз: «...выпускники Казанского театрального училища А. Кокурин, Т. Мычилкина, Н. Казанцев – правдиво и интересно создают основные образы» [Советская Татария. 1967. 14 марта]. Шул ук театрның репертуарына багышланган «Героическая тема обязывает» дигән мәкалә авторы В. Гудкова болай яза: «...выпускники Казанского театрального училища А. Кокурин и Т. Мычилкина – это актеры умеющие играть и думать на сцене» [Советская Татария. 1967. 14 марта].

Тормыш раслаганча, катлаулы, киңкырлы организм саналган театрга талантлы профессионалларыннан башка театр сәнгатенең барлык юнәлешләре буенча да уңышларга ирешү мөмкин түгел. Шуңа күрә 1964 елда көллияттә бутафор рәссамнар бүлеге ачыла. Бүлекнең оештыручысы һәм әйдәүче остасы итеп Татьяна Андреевна Зуева билгеләнә. 1968 елда бутафор рәссамнарның беренче чыгарылышы була. Т. Зуева берничә буын рәссамнар әзерли, аның шәкертләре арасыннан, театр сәнгате өлкәсендә генә түгел, сынлы сәнгать һәм график буенча да күренекле осталар үсеп чыга.

Казан театр көллияте әкренләп киңәя бара, театр өчен кирәкле белгечләр әзерләүче күп профильле уку йортына әверелә. Киң күңелле һәм талантлы педагоглар һәр укучы күңеленә ачкыч таба беләләр, аларга сәләтләрен тулысынча ачарга, һәрьяклы үсешкә ирешергә ярдәм итәләр. Көллият педагогларының төп принцибы – театр сәнгатен үстерү өчен лаеклы алмаш тәрбияләүдән гыйбарәт. Ә татар төркемендә белем алып чыккан буын милли театрларыбызның нигезен тәшкил итә, еллар узган саен алар югары дәрәҗәдәге сәнгать осталарына әйләнә баралар.

***Вәлиев Рамил Равил улы,***
*«Татар тудэй» интернет сайты корреспонденты*